Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Кәләй авыл Советы

КАРАРЫ

27октябрь 2022 ел №57

Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл Советының 2018 елның 24 августындагы 93 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыклары, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларын, депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфа окладларының акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында» карары нигезендә

Кәләй авыл Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл Советының 2018 елның 2 августындагы 93 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына (Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл Советының 2018 елның 5 декабрендәге 107 номерлы, 2020 елның 11 декабрендәге 12 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. «Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы тәртибе һәм шартлары турында»гы карарга кушымтаның 6 пункт 2 пунктчасында, 7 пункт 3 пунктчасында «(авырлыгы, киеренкелеге, хезмәттә югары казанышлары, махсус эш режимы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 1 нче кушымтадагы таблицаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

Әлмәт муниципаль районы
Кәләй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт окладлары күләме

| «Вазыйфа исеме» | Вазыйфа окладлары |
|---|---|
| | 11 группа |
| Башкарма комитет җитәкчесе | 17937,00 |
| Авыл башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары | 17579,00 |

1.3. 2 нче кушымтадагы таблицаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәре»

| «Вазыйфа исеме» | Вазыйфа окладлары |
|---|---|
| | 11 группа |
| Башлык | 17944,00 |
| Башлык урынбасары | 12894,00 |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле финанс чыгымнары белән тәэмин итү тиешле елга җирле бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге карарны Кәләй авылы, Специалистлар урамы, 2Д йорты; Сабанче авылы, Яббаров урамы, 1 йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» Интернет-телекоммуникация челтәре сайтында урнаштырырга.

4. Бу карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Кәләй авыл җирлеге башлыгы С.П. Бастылева